ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 1 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле $20^1$ пункт өстәргә:

«$20^1$) җирлек торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыкларны, алар составында булдырыла торган участок урманчылыкларын төзү, бетерү, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында карарлар кабул итү, шулай ук җирлек торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын әзерләүне һәм раслауны гамәлгә ашыру;»;

б) түбәндәге эчтәлекле $20^2$ пункт өстәргә:

«$20^2$) җирлек торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман төзелеше чараларын үткәрү;»;

2) 17 статьяның 1 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле $26^2$ пункт өстәргә:

«$26^2$) шәһәр округы торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыкларны, алар составында булдырыла торган участок урманчылыкларын төзү, бетерү, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында карарлар кабул итү, шулай ук торак пунктлар җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын әзерләүне һәм раслауны гамәлгә ашыру;»;

б) түбәндәге эчтәлекле $26^3$ пункт өстәргә:

«$26^3$) шәһәр округы торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман төзелеше чараларын үткәрү;».

**2 статья**

Әлеге Закон 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты                                                                 Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 30 сентябрь
№ 62-ТРЗ